# 2 апрель – Халыкара балалар китабы көне




Төзеде: китапханәче Каюмова Г.В.



Һанс Кристиан Андерсен (1805-1875)

**Һ.К. Андерсен1805 елның 2 апрелендә Оденсада Фюн утравында туган.**



**Китапны кем уйлап тапкан соң? Беркем дә түгел. Элек кешеләр бер-берсенә кызыклы хәлләрне сөйли торган булганнар. Шуннан соң хәрефләр уйлап чыгарганнар. Беренче кульязма китаплар күренә башлый. Китап язучылар каз каурые ярдәмендә бер китапны 6-7 ел язганнар.**




# Борынгы Ассириядә Ашшурбанипал патша балчык китаплардан торган зур китапханә булдырган. Балчык китаплар иң борынгылардан саналган.

Борынгы Һиндистанда язу өчен пальма яфраклары кулланылган.






**Египетта китапларны елга камышы – папирустан эшләгәннәр.**
**Хайван тиресе - пергаменттан да китаплар бастыралар. Бер калын китапны эшләү өчен 150 хайван тиресе кирәк булган.**


Гениальные китайцы

**Беренче кәгазьне кытайлы Цай Лунь уйлап тапкан. Кәгазь ясау технологиясен кытайлар озак еллар сер итеп саклаганнар.**

Россиядә беренче китап басу җайланмасын Иван Федоров эшли.

15 гасырда немец Иоган Гутенберг беренче тапкыр металлик хәрефләр уйлап таба.



***” МӘҢГЕ СҮНМӘС ЯКТЫ КОЯШ БУЛЫП , УЛ НУРЛАРЫН СИБӘ ЮЛЫМА”***

**(С.УРАЙСКИЙ)**

# Г.Тукай «Китап»

Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны
Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;
Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса яшь, -
Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам;
Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәтүче йолдызым;
Сөйми башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем;
Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмид берлән карый башлыйм булачакка.

***”КИТАП-БАКЧА УЛ, АНДАГЫ ЯЗУЛАР ШУЛ БАКЧАНЫҢ ГӨЛЛӘРЕ”***

**(К.НАСЫЙРИ)**



***” КИТАП МИНЕМ КУЛЫМДА, СЕРДӘШЕМ УЛ ГОМЕР ЮЛЫМДА ”***

**(С.ХӘКИМ)**

# Мәкальләр

1. Китап –
2. Китапсыз өй –
3. Күп укыган
4. Күп йөргән, күп белмәс
5. Уку күңел нуры,
   укымый калган –
6. Гыйлемлек – нур,

# Табышмаклар

1. Күрешергә кулы юк,
Сөйләшергә теле юк,
Аның белән күрешмәгән,
Белешмәгән кеше юк.



2. Кулдан-кулга йөри ул,
Бөтен телдә сөйли ул,
Белмәгәне юк аның,
Көзгесе ул дөньяның.

3.. Бик күп телләрне белсә дә,
Сөйләшми бер телдә дә.
Өйрәним, дисәң, өйрәтә,
Карышмый беркемгә дә

**Агач түгел – яфраклы,**
**Тун түгел – тегелгән.**
**Кабат-кабат катлама,**
**Акылың булса ташлама.**
**Теле юк – үзе аңлата.**
**Анда бар да бар.**
**Өнсез, җансыз – иң якын дус.**

Игътибарыгыз

өчен

рәхмәт!!!